Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советы

# КАРАР № XXXXVIII-1

Олы Елга авылы 2018 елның 21 сентябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Олы Елга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты “в” пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 19 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 68 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 68 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. . Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

“Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан гайре, һәрбер кешенең 2018 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

- Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзелешенә;

-Олы Елга, Казаклар авылларында янгынга каршы гидрантлар сатып алуга һәм урнаштыруга;

- Олы Елга, Казаклар, Сорочьи Горы авылларында суэтем скважиналары өчен тирәнлек насослары; Олы Елга авылына генератор, авыл җирлеге торак пунктларында янгын сүндерү өчен мотопомпалар сатып алуга;

- авыл җирлеге торак пунктларында урам утларына энергияне саклаучы лампалар сатып алуга һәм алыштыруга;

- Олы Елга авылының Яшьләр, Озерная, Мәктәп, Нариманов урамнарында, Кама поселогының Курортная-1 урамында юлларны ремонтлауга;

-Олы Елга авылында парк зонасын киртәләүгә;

-Олы Елга, Сорочьи Горы авылларында обелискларны тотып алуга;

-кышын авыл җирлеге торак пунктларында урамнарны карап торуга (кардан чистартуга)

юнәлтүгә Сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 нче йорт;Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт; Сорочьи Горы авылы,Үзәк урам,16А йорты; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев